**Татар гомуми белем бирү оешмаларында укучылар өчен татар әдәбиятыннан олимпиада сорауларына җаваплар (муниципаль тур, 2025-2026 уку елы) 7 нче сыйныф**

**Максималь балл – 40**

## I. Тест биремнәре (15 балл).

1. Бер яки берничә вакыйганы эченә алган, кеше характерының бер сыйфаты, ягы, аның үсү-үзгәрүе хакында сөйләүче эпик жанр (2 балл):

Җавап: **хикәя**

2. Эчке композициягә карый (1 балл):
**1) пейзаж, портрет, лирик чигенеш, диалог, монолог**
2) әдәби әсәрнең бүлекләргә, бүлекчәләргә, строфаларга һ.б. бүленеше
3) вакыйгаларның билгеле бер эзлеклелектә үсеше

3. Гомәр Бәшировның «Туган ягым – яшел бишек» әсәренең жанр формасы (2 балл):

Җавап: **автобиографик повесть**

4. Татар халык авыз иҗатының лиро-эпик жанры, фаҗигале, гыйбрәтле, гадәттән тыш хәлләр уңае белән язылган, нигезенә кайгылы яки көлкеле вакыйга салынган әсәр (1 балл):
1) җыр
2) дастан
**3) бәет**

5. Сюжетны хәрәкәткә китерә (1 балл):
**1) конфликт**
2) экспозиция
3) төенләнеш

6. Авторның сюжеттан тыш лирик, фәлсәфи, автобиографик һ.б. характердагы сүзләре, уйланулары (2 балл):

Җавап: **лирик чигенеш**

7. Кәеф, халәт, тойгы, кичереш һәм аларның үзгәрүен югалырга әзер мизгел кебек күрсәтүче, тышкы сурәт, кыяфәт, күренешне төсләр, тавышлар гармониясе ярдәмендә тергезүче модернистик агым (1 балл):
1) экспрессионизм
2) модернизм

**3) импрессионизм**

8. Төп герой тормышындагы берничә охшаш яки каршылыклы хәл, вакыйгалар тезмәсе сурәтләнгән, берничә сюжет сызыгы бер үзәк тирәсенә берләшкән эпик жанр (2 балл):

Җавап: **<u>повесть</u>**

9. Рөстәм Галиуллинның «Сәлам...» әсәренең жанры (1 балл):

1) нәсер

**2) хикәя**

3) повесть

10. *Бүген беренче октябрь. Без, аркага капчыкларыбызны асып, кемнеңдер теләге буенча укырга килдек. Үгезләрдән, дегет, камыл исеннән, күксел урманнардан, зәңгәр төтенле, көйгән бәрәңге исе килеп торган басулардан безне кем аерды? Ник аердылар? Моны беребез дә белми иде.*

*Җәй буе борчак, яңа бәрәңге, әвендә киптерелгән, төтен тәме сеңгән яңа арыш умачы ашап, капчык күтәреп тән ныгып беткән – бүген әнә шул көчне кая куярга белгән юк...* Әлеге өзек кайсы авторның нинди әсәреннән алынган? (2 балл):

Җавап: **<u>Мөхәммәт Мәһдиев «Без – кырык беренче ел балалары»</u>**

## II. Язма җавапка бәйле биремнәр (25 балл).

1. Теоретик төшенчә буларак сюжет һәм сюжет элементлары. Ибраһим Газиның «Ак сирень» хикәясендә сюжет элементларын табып языгыз (10 балл).

*<u>Сюжет – вакыйга-хәлләр яки кеше холкы-характерының үсү-үзгәрү тарихы. Сюжет элементлары:</u>*

*<u>Пролог – әсәрдә сөйләнәчәк тарихтан бик күпкә элек булган вакыйгаларны ниндидер максат белән әсәр башында сөйләп кую;</u>*

*<u>Экспозиция – конфликтны барлыкка китерүче сәбәпләр, аның алшартлары белән таныштыру;</u>*

*<u>Төенләнеш – конфликтның башлану ноктасы;</u>*

*<u>Вакыйгалар үстерелеше – конфликтның зураю, тирәнәюе, аны чишәргә омтылышлар ясалу;</u>*

*<u>Кульминацион нокта – әсәрдәге вакыйгаларның, көрәшнең иң югары ноктасы;</u>*

*<u>Чишелеш – конфликтка нокта куелу, проблеманың хәл ителүе. Ул я конфликтның юкка чыгуын, я чишелә алмаслыгын күрсәтә;</u>*

*<u>Эпилог – соңгы нәтиҗә, геройларның алдагы язмышларын хәбәр итү яки автор мөнәсәбәтен ачыклау.</u>*

Ибраһим Газиның «Ак сирень» хикәясендә сюжет элементлары:

*Экспозиция – Сания исемле кыз турында сөйләү;*

*Төенләнеш – Көлтә башлы егетнең Санияләр тәрәзә төбеннән үтеп китмәве;*

*Вакыйгалар үстерелеше – Саниянең ашкынып урамга чыгып китүе, кинотеатр каршына килеп туктавы;*

*Кульминацион нокта – Саниянең сөйгәнен башка кыз белән күрүе, хисләренең җавапсыз икәнен белүе;*

*Чишелеш – Саниянең өенә кайтып китүе, ишегалдында бик озак үзенә урын таба алмыйча йөреп, таш стенага маңгаен терәп үксеп елап җибәрүе.*

2. Ибраһим Газиның «Ак сирень» хикәясендә ак сирень образының мәгънәсен ачыклагыз. Көчле позициягә чыгарылган әлеге образ әсәрдә нинди функция үти дип уйлыйсыз? (5 балл):

*Ибраһим Газиның «Ак сирень» хикәясендә ак сирень образы көчле позициягә – әсәрнең исеменә чыгарылган. Әлеге образ Саниянең беренче мәхәббәт хисенең сафлыгын, самимилеген күрсәтә. Яшүсмер кызның эчке дөньясының аклыгын, ихласлыгын ачарга мөмкинлек бирә.*

3. Ибраһим Газиның «Ак сирень» хикәясендәге үзегез теләгән бер геройга характеристика бирегез (5 балл):

*Укучы үзе теләгән геройга характеристика бирергә тиеш.*

4. Ибраһим Газиның «Ак сирень» хикәясендә автор фикерен – идеяне билгеләгез. Ул нинди каршылык аша ачылып китә? (5 балл):

*Ибраһим Газиның «Ак сирень» хикәясендә төп эчке конфликт Саниянең хыялы һәм чынбарлык арасында барлыкка килә. Әлеге каршылыкны сурәтләү барышында язучы, кешенең матур хыяллар белән яшәве, әмма тормыш кануннарының кырыс һәм аяусыз булуы турында сөйли. Тормышта күп кенә хыяллар чынга аша алмый кала, юкка чыга, әмма хыяллар белән яшәү кешене матур итә, аны тормышның матурлыгын тоярга өйрәтә, ди автор. «Ак сирень» хикәясендә автор фикере мәхәббәткә бәйле җиткерелә. Мәхәббәт – кешене үзгәртүче татлы да, газаплы да хис, ул, хәтта җавапсыз булса да, кешенең күңелен нечкәртә, аны матур хисләр дөньясында яшәүгә этәрә. Бу – әсәрнең төп идеясе.*

**Татар гомуми белем бирү оешмаларында укучылар өчен татар әдәбиятыннан олимпиада сорауларына җаваплар (муниципаль тур, 2025-2026 уку елы) 8 нче сыйныф**

**Максималь балл – 43**

## I. Тест биремнәре (18 балл).

1. Халык авыз иҗатында эпик характердагы жанр, гадәттә әкият сюжетларын, риваять-легендаларны әдәби эшкәртеп язылган романтик эчтәлекле әсәр (2 балл):

Җавап: **дастан**

2. Әдәби әсәрдә пейзажның функциясе (1 балл):
1) әсәрне эстетик яктан бизи
**2) геройның эчке халәтен ачарга ярдәм итә**
3) әсәрнең тел-стилен камилләштерә

3. «Таһир белән Зөһрә» әсәре дастаннарның кайсы төренә карый? (2 балл):

Җавап: **мәхәббәт дастаны**

4. Әдәби әсәрдә кешенең тышкы кыяфәтен тасвирлау (2 балл):

Җавап: **портрет**

5. Тышкы кыяфәт аркылы эчке халәтне бирү (2 балл):

Җавап: **психологик портрет**

6. Әдәби әсәрдә кешене чолгап алган әйберләр (2 балл):

Җавап: **әйберләр дөньясы**

7. Әдәби әсәрдә портретның функциясе (1 балл):
1) йөз матурлыгын ачып бирә
2) геройның эчке дөньясындагы уйларның тәртипсез хәрәкәтен күрсәтә
**3) укучының герой турында күзаллавын тудыруда ярдәм итә**

8. «Идегәй» әсәренең жанр формасы (2 балл):

Җавап: **тарихи дастан**

9. Нурихан Фәттахның «Итил суы ака торур» романында төп символик образ (2 балл):

Җавап: **Идел елгасы, Идел суы**

10. *Шулай да карчыкка җиңел түгел иде. Туган туфрак никадәр генә үзенә бәйләмәсен, авыл артындагы канау белән әйләндереп алган зиратта ятучы әрвахлар нихәтле генә якын булмасын, әмма болар гына аның тормышын тутыра, ялгызлыгын җиңеләйтә алмыйлар иде. Ялгыз башын монда асраса да, күңеле белән ул һаман шул балалары янында иде. Шуларны уйлап, шуларны сагынып, шыксыз озын көзләрне дә, салкын кышларны да уздырып җибәрә; сабыр гына җәйне көтеп ала, ә җәен берәр улымы яки кызымы балалары белән кайтып китәргә тиеш аның...* Әлеге өзек кайсы авторның нинди әсәреннән алынган? (2 балл):

Җавап: **Әмирхан Еники «Әйтелмәгән васыять»**

**II. Язма җавапка бәйле биремнәр (25 балл).**

1. Теоретик төшенчә буларак конфликт. Фатих Хөснинең «Йөзек кашы» повестенда эчке һәм геройлар арасындагы тышкы конфликтларны табып языгыз (10 балл).

*Конфликт – вакыйга-күренешләр нигезенә салынган характерлар һәм хәлләр, геройларның эш-гамәлләренең, карашларының һәм тормыш принципларының каршылыкка керүе. Ул геройлар арасында, кеше һәм тирәлек, кеше һәм яшәү рәвеше арасында, яки геройның үз эчендә булырга мөмкин.*

*Төп тышкы конфликтлар:*

*Айдар – Вәсилә*

*Айдар – Госман*

*Госман – Вәсилә*

*Төп эчке конфликт:*

*Айдарның күңелендә барган каршылык*

*Вәсилә күңелендә барган каршылык*

2. Фатих Хөснинең «Йөзек кашы» повестенда йөзек кашы образының мәгънәсен ачыклагыз. Көчле позициягә чыгарылган әлеге образ әсәрдә нинди функция үти дип уйлыйсыз? (5 балл):

*Йөзек кашы – әсәрдә мәхәббәт, беренче мәхәббәтнең, яшьлекнең сафлыгы символы. Госман йөзекне, үзенә сиздермичә генә, Вәсиләнең кулыннан салдырып ала. Ул аның йөзеген тартып кына алмый, аның яшьлек мәхәббәтенә, яшьлек сафлыгына кул суза.*

3. Фатих Хөснинең «Йөзек кашы» повестендагы үзегез теләгән бер геройга характеристика бирегез (5 балл):

*Укучылар үзләре теләгән геройга характеристика бирергә тиешләр.*

4. Фатих Хөснинең «Йөзек кашы» повестенда автор фикерен – идеяне билгеләгез. Ул нинди проблемалар аркылы ачыла? (5 балл):

*Фатих Хөсни әлеге әсәрендә көнчелек, рухи әшәкелек, акыл белән эшләмәү, дуамаллык, эгоистлык, гаделсезлек, тугрылык һәм хыянәт һ.б. проблемалар күтәрә.*

*Әсәрнең төп идеясе: йөзек кашы булырдай мәхәббәтне саклау, бәхетле булу үзебездән тора, ашыгып карарлар кабул итмәскә кирәк, һәр кеше үзендә бәхетсезлекләрне ерып чыгарлык ихтыяр көче тәрбияләргә тиеш.*

**Татар гомуми белем бирү оешмаларында укучылар өчен татар әдәбиятыннан олимпиада сорауларына җаваплар (муниципаль тур, 2025-2026 уку елы) 9 нчы сыйныф**

**Максималь балл – 48**

## I. Тест биремнәре (18 балл).

1. Бер тарихи вакыт аралыгында әдәбиятта барган үзгәрешләр. Әдәбиятның билгеле бер юнәлештә үсүе, әдәби закончалыклар һәм хасиятләрнең бер әсәрдән – икенчесенә, бер иҗаттан – икенчесенә, бер чордан икенче чорга күчеп, аны баета һәм үзгәртә баруы (2 балл):

Җавап: **<u>әдәби барыш</u>**

2. Билгеле бер дингә мөнәсәбәтле өйрәтүләрне үз эченә алган, яшәеш кануннарын Аллаһ кодрәтенә бәйләп аңлатучы, укучыны да дин кагыйдәләре, дин тарихы белән таныштыруны максат иткән әдәбият (1 балл):

1) урта гасыр төрки-татар әдәбияты
**2) дини әдәбият**
3) дөньяви әдәбият

3. Болгар чоры әдәби ядкәре. Авторын һәм әсәрнең исемен язып куегыз (2 балл):

Җавап: **<u>Кол Гали «Кыйссаи Йосыф»</u>**

4. Милли төрки әдәбиятлар барлыкка килгәнче яшәгән, төрки халыкларның уртак мәдәни мирасы, төрки әдәбиятлар үсешенең нигезе (2 балл):

Җавап: **<u>гомумтөрки әдәбият</u>**

5. Әдәби әсәрдә табигать күренешләренең сурәтләнеше (2 балл):

Җавап: **<u>пейзаж</u>**

6. Әдәби әсәрдә геройның тышкы кыяфәтен сурәтләү (2 балл):

Җавап: **<u>портрет</u>**

7. Яшәеш кануннарын фәнни нигездә аңлатучы, кешенең иҗтимагый, мәдәни, аң эшчәнлеген Аллаһ йогынтысына мөнәсәбәтле карамый торган әдәбият (1 балл):

1) урта гасыр төрки-татар әдәбияты
2) дини әдәбият
3) **дөньяви әдәбият**

8. Көрәш идеяләрен тормышка ашыруга гомерен багышлаган, көрәш ярдәмендә иске тәртипләргә каршы күтәрелгән романтик герой. Мондый тип лирик герой Сәгыйть Рәмиев иҗатында актив чагылыш таба (2 балл):

Җавап: **гыйсъянчы, бунтарь лирик герой**

9. Мәүла Колый иҗатындагы төп жанр (2 балл):

Җавап: **хикмәт**

10. *Тәгәрәп аунап*
*Буй үскән,*
*Туган илем, исән бул!*

*Чәч кузгатып,*
*Җай искән,*
*Таңгы җилем, исән бул!*
*Йөгереп - йөгереп туктаган...*
*Яулык болгап сыктаган,*
*Нәзкәй билем, исән бул!* ... Әлеге шигырьнең исемен һәм авторын языгыз (2 балл):

Җавап: **Дәрдемәнд «Видагъ»**

## II. Язма җавапка бәйле биремнәр (30 балл).

1. Мәгърифәтчелек реализмы һәм аңа хас үзенчәлекләр. Әлеге үзенчәлекләрне Муса Акъегетнең «Хисаметдин менла» әсәре мисалында аңлатып языгыз (10 балл).

*Татар әдәбиятындагы мәгърифәтчелек реализмы кысаларында иҗат ителгән әсәрләрдәраслаучы пафос, идея өстенлек итә: гыйлемлелек, мәрхәмәтлелек мактала, әхлакый нәтиҗәләр сүз катламында да кабатлана. Төп конфликт акыллы, белемле һәм надан, тәрбиясез геройлар, искелек белән яңалык арасында формалаша һәм акыллы геройның яки яңалыкның җиңүе белән тәмамлана. Әсәрләргә шартлылык хас булып, геройлар да уңай яки тискәрегә кискен аерыла, аларның эш-гамәлләре, язмышы да мотивлаштырылган була. Уңай геройлар гел уңай сыйфатлардан гына тора. Кешенең әхлакый камиллеген белем алу белән бәйләнештә карау, җәмгыятьне үзгәртү эшен гаиләдән башлау мотивлары әйдәп бара. Кеше бәхете дә аң-белем һәм тәрбиягә мөнәсәбәтле аңлатыла һ.б.*

*Әлеге әсәрдә дә бу сыйфатлар ачык чагылыш таба. Мәсәлән, уңай геройлардан Хисаметдин белән Хәнифә гел уңай сыйфатлардан гына тора. Хисаметдин укымышлы, белемле, акыллы, тәрбияле герой. заман яңалыклары белән хәбәрдар, газеталар алдырып алар белән танышып бара, игенчелек хезмәте белән шөгыльләнә, үз өендә яңа ысул белән (җәдитчә) балалар укыта. Тормышын да укымышлы кыз белән бәйли, дуслары да үзе кебек халыкны наданлыктан чыгару, авыр хәлдә калганнарга (Мохтар) дөрес юл күрсәтү белән шөгыльләнәләр.*

*Хәнифә зифа буйлы, чибәр булу өстенә укымышлы, уңган һәм иң мөһиме - үз бәхете өчен көрәшүче, киләчәге турында тирәнтен фикер йөртергә сәләтле. Укыйяза белүе, тәвәккәллеге һәм сүзендә нык торуы аңа язмышын үзе теләгән юлдан алып барырга ярдәм итә. Әсәрдә хатынкыз ирееге мәсьәләсе Хәнифә образында гәүдәләнә. Муса Акъегет татар әдәбиятында беренчеләрдән булып Хәнифә образында иске гореф-гадәтләрне кире кагып, үз бәхете өчен көрәшкән һәм җиңеп чыккан татар кызын иҗат итә.*

*Әсәрдә конфликт Хисаметдин белән Бикбулат хәзрәт арасында, ягъни искелек белән яңалык арасында. Ул Хисаметдиннең Бикбулат хәзрәт белән булган бәрелешләрдә аны җиңеп чыгуы белән чишелә.*

*Муса Акъегет, татар әдәбиятында беренчеләрдән булып, үз заманының әһәмиятле мәсьәләләреннән булган җәдитчелек һәм кадимчелек каршылыгын чагылдырып, киң катлам халыкны белемле итү, хатын кыз ирееге, гаилә коруда шәхси теләк, фикери уртаклыкны яклап чыга. Бу мәсьәләләрне хәл итүне автор тормышчан вакыйгалар, реалистик геройлар һәм аларның эшгамәлләре аша ачып бирә.*

2. Муса Акъегетнең «Хисаметдин менла» әсәрендә төп конфликт. Ул кемнәр арасында барлыкка килә һәм үсә? (5 балл):

*Әсәрдә конфликт Хисаметдин белән Бикбулат хәзрәт арасында, ягъни искелек белән яңалык арасында. Авылның карт мулласы Бикбулат хәзрәт Хисаметдингә мөмкин кадәр каршылык күрсәтә. Авыл халкы алдында хурлый, абруен төшерә, надан итеп күрсәтергә, эш-гамәлләрендә кимчелек табып, аларны халык алдында фаш итәргә тели. Шуның белән ул дәрәҗәсен күтәрергә, авыл халкын үзенә каратып, иске тәртипләргә буйсындырып яшәтергә омтыла. Әсәрдә төп конфликт - искелек һәм яңалык көрәше. Үзенең акылы, гыйлеме, сабырлыгы, уйлап эш итүе нәтиҗәсендә Хисаметдин Бикбулат хәзрәт белән булган бәрелешләрдә җиңеп чыга. Бу конфликт аша автор искелеккә ябышып ятмау, дөньяви белемнәрне үзләштерү кирәклеген дәлилли.*

3. Муса Акъегетнең «Хисаметдин менла» әсәрендәге үзегез теләгән бер геройга характеристика бирегез (5 балл):

*Укучылар үзләре теләгән геройга характеристика бирергә тиешләр.*

4. Муса Акъегетнең «Хисаметдин менла» әсәрендә автор фикерен – идеяне аңлатып языгыз (5 балл):

*Хисаметдин белән Хәнифә икесе дә — укымышлы, искелектән килгән, кеше ирегенә һәм бәхетенә каршы куелган киртәләрне үтә алырлык көчле ихтыярлы, яңа заман геройлары.*

*М. Акъегетзадә, милли алгарышны югары әхлаклы, белемле һәм һөнәрле, ирекле шәхес кенә тудыра ала. Шәхси бәхет тә, халыкның бәхете дә аң-белем һәм тәрбиягә бәйле. Моның өчен милләтнең үз укымышлылары булырга тиеш, дип раслый.*

5. Бүген актив иҗат эше белән шөгыльләнә торган (урта һәм яшь буын) 3 шагыйрьнең һәм 2 язучының исем-фамилиясен языгыз (5 балл).

**Татар гомуми белем бирү оешмаларында укучылар өчен татар әдәбиятыннан олимпиада сорауларына җаваплар (муниципаль тур, 2025-2026 уку елы) 10 нчы сыйныф**

**Максималь балл – 50**

## I. Тест биремнәре (18 балл).

1. Әсәрнең эмоциональ көйләнеше, яңгырашы, аһәңе. Үз фикерен укучыга җиткерү өчен, язучы билгеле бер яңгыраш дулкыны таба да, әсәрнең башка элементларын шуңа яраклаштыра, әсәрнең идеясен аңлауда ярдәм итә, укучыга идеягә мөнәсәбәтле хискә авторның кичерешләрен җиткерә (2 балл):

Җавап: **<u>пафос</u>**

2. Габдулла Тукайның «Кыйтга» шигыре әдәбиятның кайсы чорына карый (1 балл):

1) XIX гасырның икенче яртысы
2) 1920 еллар
**3) XX йөз башы**

3. Әдәби әсәрдә кешенең эчке дөньясын ачуга хезмәт итә торган алымнар берлеге; язучының кеше күңеленә үтеп керү, аның халәт-кичерешен сурәтләү осталыгы (2 балл):

Җавап: **<u>психологизм</u>**

4. Аның романтизмының төп үзенчәлеге – чынбарлык белән сәнгать арасындагы мөнәсәбәтнең асылына төшенеп, тормышны үз табигый сыныннан күтәребрәк сурәтләү. Лирик герое – галәм, җир турында уйланып, борчылып яшәүче шул ук галәм һәм җир кешесе. Ул үзен кешеләр язмышы, аларның киләчәге өчен җаваплы саный. Кайсы әдип турында сүз бара? (2 балл):

Җавап: **<u>Илдар Юзеев</u>**

5. Лирикада авторның аңын, рухи тәҗрибәсен, дөньяны аңлавын һәм аңа карашын, фикерен үз эчке дөньясы, хис-кичерешләре, сөйләме аша җиткерүче әдәби образ (2 балл):

Җавап: **<u>лирик герой</u>**

6. Күпсанлы ассоциатив сыйфатларны берләштерүче күпмәгънәле, гомуми шартлы образ, туры мәгънәсеннән тыш, аңа бәйле булмаган

күчерелмә мәгънә аңлата, аллегориядән аермасы да мәгънәләрнең берничә булуында (2 балл):

Җавап: **<u>символ</u>**

7. Әсәрдә кызгану, аңларга тырышу хисләренең өстенлек алуы. Бу хисләрне геройлардагы матурлык һәм көчсезлек, яки тышкы ямьсезлек һәм рухи матурлык, намуслылык берлеге китереп чыгара (1 балл):

1) романтик пафос
**2) сентименталь пафос**
3) фаҗигале пафос

8. Стилистик фигура, җавап алу максаты белән түгел, ә бәлки теге яки бу күренешкә укучының яки тыңлаучының игътибарын юнәлтү максаты белән куелган сорау (2 балл):

Җавап: **<u>риторик сорау</u>**

9. Илдар Юзеевның «Өчәү чыктык ерак юлга» әсәренең жанры (2 балл):

Җавап: **<u>поэма</u>**

10. *Икенче көнне иртүк кияү чәенә Сәгыйдәне алырга килгән атка утырып баргач, калтырабрак, аптырабрак каршы чыккан Зөлфия абыстайга да ул һаман элгәрерге кебек көләч йөз белән: «Исәнме?» – диде. Өй арасында йөри торган Зөлфия абыстайның килененең кызын да элгәрерге кебек итеп сөйде.*

*Хәзрәт бикәчли торган өйнең ишегенә җиткәч кенә, бердән, алдында упкын ачылган кешедә була торган кебек кот очу аны биләде. Шул өйгә, шул ишеккә каршы бөтен тәне-җаны дошманлык белән тулды…* Әлеге әсәрнең исемен, авторын һәм жанрын языгыз (2 балл):

Җавап: **<u>Гаяз Исхакый “Остазбикә”, повесть</u>**

## II. Язма җавапка бәйле биремнәр (32 балл).

1. Теоретик төшенчә буларак хронотоп. Аның үзенчәлекләрен Гали Рәхимнең «Идел» повесте мисалында аңлатып языгыз (10 балл).

*<u>Хронотоп (грекч. chronos – вакыт, topos – урын) – әдәбиятта чагылдырылган бербөтен урын һәм вакыт хакындагы күзаллау; әдәби әсәр дөньясының әһәмиятле параметры. Әдәби әсәрдә урын һәм вакыт гадәттә бергә табыла.</u>*

*<u>Урын-вакыт ике төрле була: төгәл билгеләнә торган урын-вакыт һәм абстракт урын-вакыт. Төгәл билгеләнә торган урын-вакытка геройның</u>*

*биографик вакыты белән бәйле календарь вакыт, әсәрдә барган вакыйгалар вакыты, ә абстракт вакытка хикәләүченең вакыты — перцептуаль вакыт керә. Бу пространствоны (урынны) төгәл билгеләүгә китереп, әсәрдә сөйләнгән вакыйгаларны, геройның күңел халәтен аңларга ярдәм итә.*

*Перцептуаль хронотоп субъектив урын һәм вакыт буларак, әсәр геройлары белән булган психологик процессларга бәйле. Ул, субъектның тышкы һәм эчке тәҗрибәсен билгеләп, художестволы образ формасында чагылыш таба. Әсәрләрдә перцептуаль хронотоп геройларның хатирәләре, уйлары, хыяллары, төшләре, саташулары рәвешен ала.*

*Гали Рәхимнең «Идел» повестенда перцептуаль хронотоп геройларның уйланулары, хыяллары, төшләрендә чагылыш таба. «Идел»дә календарь вакыт 1914 ел белән билгеләнә, вакыйгалар яздан алып көзгә кадәр сузыла. Психологик вакыт исә бөтен әсәрне чолгап, камап алган, чиктән тыш киңәйтелгән, әкеренәйтелгән кебек тәэсир кала. Вакыт үзе берничә капма-каршылыклар арасында тирбәлә: тынычлык һәм сугыш (календарь); яз һәм көз (вакыйгалар); яшьлек һәм картлык, ирек һәм мәхәббәт, мәхәббәт һәм ялгызлык (психологик) алар. Беренче карашка кала – табигать кочагы кебек аерылган романтик урын Идел, ягъни элек-электән татарлар яшәгән җир, Ватан булып гомумиләшә. һ.б.*

2. Гали Рәхимнең «Идел» повестенда көчле позициягә чыгарылган Идел образы. Автор аңа нинди мәгънәләр сала? (5 балл):

*Идел әсәрдә мәхәббәт символы булып аерылып чыга. Ильясның авылдан соңгы тапкыр китү вакыйгасында мәхәббәт шаһите булган елга –ана мәгънәсендә яңгырый. «Менә ул безнең олуг анабыз, Идел, минем аяк астымда... Син безнең туган Иделебез, үз Иделебез идең ләбаса, ник үзеңнең балаларыңны ташладың? Ник безне әллә кемнәр синең шәфкатьле ярларыңнан сөрделәр?» Мәхәббәтне җуйганга үкенеч милләт өчен үкенү-борчылу хисе белән кушыла. Сюжеттагы кыз-егет мәхәббәте белән янәшә милләткә мәхәббәт дигән яңа бер хис турында сөйләнә. Моннан тыш ул гомер агышы, язмыш мәгънәләрендә дә кулланыла һ.б.*

3. Гали Рәхимнең «Идел» повестендагы үзегез теләгән бер геройга характеристика бирегез (5 балл):

*Укучы үзе теләгән геройга характеристика бирергә тиеш*.

4. Гали Рәхимнең «Идел» повестенда теманы билгеләгез һәм аңлатып языгыз (5 балл):

*Әсәрнең төп темасы – мәхәббәт. Язучы кешене дөньяда яшәткән ике омтылыш: мәхәббәт һәм ирек; ике хис: ярату һәм үкенеч хакында сөйли. Сюжет катламында бирелгән вакытлы кыз–егет яратуы һәм гомер буе дәвам итүче милләтне ярату әсәрнең тематик үзенчәлеген билгели. Әсәрнең*

*иceмe һәм эпиграфның да, әсәрне укып бетергәннән соң, милләткә карата кулланылган булуы ачыклана.*

5. Бүген актив иҗат эше белән шөгыльләнә торган (урта һәм яшь буын) 4 шагыйрьнең һәм 3 язучының исем-фамилиясен языгыз (7 балл).

**Татар гомуми белем бирү оешмаларында укучылар өчен татар әдәбиятыннан олимпиада сорауларына җаваплар (муниципаль тур, 2025-2026 уку елы) 11 нче сыйныф**

**Максималь балл – 50**

**I. Тест биремнәре (18 балл).**

1. Әдәби белдерү алымнары һәм чараларының бөтенлеге, бу төшенчә белән сүзләр ярдәмендә фикер-хисләрне белдерү рәвешен; сөйләмә һәм язма телдә сөйләм оештыру юлларын; әдәби текстның форма үзенчәлекләрен билгеләү яшәп килә (2 балл):

Җавап: **стиль**

2. Габдулла Тукайның «Өзелгән өмид» шигыре әдәбиятның кайсы чорына карый (1 балл):
1) XIX гасырның икенче яртысы
2) 1920 еллар
3) **XX йөз башы**

3. Аерым кешеләрнең шәхси теләк-омтылышлары, язмышы һәм тирәлек белән бәрелеше сурәтләнгән, шулар аша кеше һәм җәмгыятькә бәя бирелә, холык-фигыль ачыла торган зур күләмле эпик әсәр (2 балл):

Җавап: **роман**

4. Талантлы шагыйрь, матбагачы, хәйрияче, алтын приискалары хуҗасы, XX йөз башы татар мәдәни күтәрелешен матди яктан тәэмин итүчеләрнең берсе. Кайсы әдип турында сүз бара? (2 балл):

Җавап: **Дәрдемәнд**

5. Батырлыкка дан җырлауга, кешенең бөеклеген раслауга юнәлтелгән, аерым кеше яки кешеләр төркеменең үз идеалларын яклап көрәшү тарихы күрсәтелгән әсәрләрдә яңгырый торган пафос төре (1 балл):
1) романтик пафос
**2) героик пафос**
3) трагик пафос

6. Яшәүнең мәгънәсен эзләүче ялгыз шәхес фаҗигасе үзәктә яткан, яшәешнең ялгыш кануннарга корылганы өчен кайгыручы, куркучы, чарасызлык баскычына атлаучы шәхеснең рухи дөньясы, сызлануы турында сөйләүче модернистик агым (2 балл):

Җавап: <u>**экзистенциализм**</u>

7. Психологизмның өченче заттан кешенең күңел хәрәкәтен җентекле сөйләп-күрсәтеп баруга корылган алымы (2 балл):

1) үзанализ

**2) психологик анализ**

3) психологизм

8. Кайсы лирик жанрда лирик герой бер төркем, милләт, иҗтимагый катлау вәкиле булып, шулар исеменнән сөйли? (2 балл):

Җавап: <u>**гражданлык лирикасы**</u>

9. Һади Такташның «Югалган матурлык» әсәренең жанры (2 балл):

Җавап: <u>**драма**</u>

10. *...«Сез кайсы халыктан?» – дисәләр,*
*Батырлар исемен атадым.*
*Батырлар утларга керделәр»*
*Тик исән булсын, дип, Ватаным....* Әлеге әсәрнең исемен, авторын һәм жанрын языгыз (2 балл):

Җавап: <u>**Разил Вәлиев “Ватаным”, гражданлык лирикасы**</u>

## II. Язма җавапка бәйле биремнәр (32 балл).

1. Жанр буларак драма. Аның үзенчәлекләрен Кәрим Тинчуринның «Сүнгән йолдызлар» әсәре мисалында аңлатып языгыз (10 балл).

<u>*Драма – җитди конфликтка корылган жанр. Бер төркем, катлау вәкилләре булган кешеләр арасында чыккан конфликт үткен проблемалар куярга, тамашачыны уйландырырга ярдәм итә. Чишелеш бер төркемгә – тамашачының гаепләвен, бер төркемгә – соклану уята, яки яхшылык җиңеп чыга. Драмаларда тышкы һәм эчке конфликтлар чагылыш таба, әмма эчке конфликт төп конфликт була һ.б. Шушы билгеләрне укучылар драма мисалында аңлатып бирергә тиешләр.*</u>

2. Кәрим Тинчуринның «Сүнгән йолдызлар» драмасында төш образы. Автор аңа нинди мәгънәләр сала? (5 балл):

<u>*Драма Исмәгыйльнең төш күрүе белән башланып китә. Төш әсәрдә күчерелмә мәгънәгә ия һәм символик функциядә кабул ителә. Төштә аждаһаның йолдызларны сүндерүе, Исмәгыйльнең, Сәрвәрнең, Надирның һәм башка бик күп егетләрнең йолдызлары сүнүе, күк йөзен караңгылык каплап алу драманың төп сюжет сызыгында булачак күңелсез вакыйгаларга, сугыш*</u>

*тартып алган мәхәббәткә, егетләрнең үлеменә ишарә булып тора. Аҗдаһа сугышны аңлата, сүнгән йолдызлар – кешеләрнең сүнгән бәхетләре ул.*

3. Кәрим Тинчуринның «Сүнгән йолдызлар» драмасындагы Сәрвәр яки Надир образларына характеристика бирегез. Аңа үз мөнәсәбәтегезне дә белдерегез (5 балл):

*Укучылар үзләре сайлап алган геройга характеристика бирергә һәм аның адымнарына карата үз мөнәсәбәтләрен аңлатырга тиешләр.*

4. Кәрим Тинчуринның «Сүнгән йолдызлар» драмасында автор позициясен – идеяне билгеләгез һәм аңлатып языгыз (5 балл):

*Кешеләр арасындагы аңлашылмаучылык аерым берәүләрнең бәхетен җимерсә, сугыш халыкны, илне бәхетсезлеккә төшерә. Кешеләрнең бәхетсезлеге – тормыш гаделсезлегендә.*

5. Бүген актив иҗат эше белән шөгыльләнә торган (урта һәм яшь буын) 4 шагыйрьнең һәм 3 язучының исем-фамилиясен языгыз (7 балл).